ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче утырышы көн тәртибе турында

---

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы унбишенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 115-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
3. «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 116-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 121-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 124-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 119-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 31 статьясына үзгәреш кертү хакында» 120-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 117-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 118-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының $141^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 123-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 122-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. Профессиональ даими нигездә эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын сайлау турында.

13. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым комитетлары составларындагы үзгәрешләр турында.

14. Табигатьтән файдалану өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең Идел-Кама регионара идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүмат.

15. Махсус хәрби операциядә катнашучы абонентка бирелгән абонент номеры (номерлары) буенча элемтә хезмәтләреннән файдаланмаган очракта, кәрәзле элемтә хезмәтләрен күрсәтү турындагы шартнамәне элемтә операторы тарафыннан берьяклы тәртиптә өзүгә тыю билгеләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Брянск өлкә Думасы мөрәҗәгате хакында.

16. «Хезмәткә вакытлыча сәләтсезлек очрагында һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерү турында» Федераль законның $1^{1}$ һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1036837-8 номерлы федераль закон проекты турында (аерым иминият очраклары барлыкка килгәндә аерым категориядәге гражданнарның мәҗбүри социаль иминият буенча хокук мөнәсәбәтләренә ихтыярый керү экспериментларын үткәрү мөмкинлеген билгеләү хакында).

17. «Хезмәткә вакытлыча сәләтсезлек очрагында аерым категориядәге гражданнарның мәҗбүри социаль иминият буенча хокук мөнәсәбәтләренә ихтыярый керү экспериментын үткәрү турында» 1036780-8 номерлы федераль закон проекты хакында («Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы гражданнарга хезмәткә вакытлыча сәләтсезлек очрагында мәҗбүри социаль иминият буенча хокук мөнәсәбәтләренә ихтыярый керү мөмкинлеген бирү турында).

18. «Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Арбитраж процессуаль кодексына үзгәрешләр кертү хакында»

1023759-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларында эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләрнең вәкаләтләрен киңәйтү өлешендә).

19. «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1023998-8 номерлы федераль закон проекты турында (туристлык продуктлары һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләре турында мәгълүмат агрегаторлары эшчәнлеген җайга салу хакында).

20. «Этил спирты, алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 1041212-8 номерлы федераль закон проекты хакында (алкоголь продукциясен ваклап сатуга лицензия һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуга лицензия алу процедурасын оптимальләштерү турында).

21. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү өлкәсендәге программаларны гамәлгә ашыру турында».

22. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 29 октябре
№ 423-VII ДС